*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү тәрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*Гыйнвар, 2025 ел*

*№ 3*



***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

**Бу санда:**

- Яңа елның хуҗасы-яшел төстәге Агач елан
- 2025 ел - « Ватанны саклаучылар» елы
- Бакчабызда искечә яңа ел
- « Новогодняя феерия » конкурсында III урын
- « Кышлаучы кошлар » безнең дусларыбыз
- Кошлар килгән җимлеккә
- Шагыйрә Гөлчирә Нәҗметдинова белән очрашу кичәсе

Хуш киләсең, Елан елы,
Сине каршы алабыз.
Барчагызга сәламәтлек,
Бәхет теләп калабыз!
Яхшы хәбәр , вакыйгалар,
Илләрдә булып торсын!
Хәвеф -хәтәр, бәла- каза,
Сездән еракта йөрсен!
Котлы булсын, Яңа еллар,
Эшләрегез уң булсын!
Тик бәхетле мизгелләрдән,
Безнең гомерләр торсын!

Флария Терегулова



**Яна 2025 елның хуҗасы-яшел төстәге Агач елан**

Елан бик акыллы, хәйләкәр һәм зирәк җан иясе. Көнчыгыш әкиятләрендә ул – кешеләргә кыен чакта юл күрсәтүче, авыр вакытта ярдәм итүче. Өстәвенә, елан кызыксынучан, сабыр, һәрбер ситуациядән чыгу юлын таба белә. Чын тормышта елан кешеләрне куркытырга да сәләтле. Ләкин ул тик торганнан гына һөҗүм итми, башта кисәтә. Еланнан зыян күрмәс өчен, аның кисәтүенә игътибарлы булырга гына кирәк. Ел хуҗасы безгә карата миһербанлы булырга охшаган. Ул яшел төстә. Яшел төс – тынычлык төсе, гармония, яшәү һәм өмет төсе. Өстәвенә, ул әле Агач елан. Агач – үсешкә омтылу, яшәеш, озын гомер символы.

Димәк, 2025 ел тарихка тынычлык, үсешкә ирешү, гармонияле ел булып кереп калыр. Без моңа бик өметләнәбез.

## 2025 ел — «Ватанны саклаучылар» елы.

Тәкъдим РФ Президенты Владимир Владимирович Путин инициативасы белән Кремльдә Дәүләт Советы утырышында кабул ителде. «Киләсе елда без Бөек Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтәчәкбез. Шуңа бәйле рәвештә 2025 елны- «Ватанны саклаучылар елы» дип игълан итәргә тәкъдим итәм! , – диде Владимир Владимирович Путин. Бүген безнең геройларыбыз һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм төрле тарихи чорларда Ватан өчен сугышкан, әтиләребез, бабаларыбыз, нацизмны җимергән солдатларыбыз даны өчен көрәшкән батырлыклары истәлегенә.

Татарстан Рәисе-Рөстәм Миңнеханов та 2025 елны - «Ватанны Саклаучы» елы дип игълан итте. Бу хакта ул 2025 елга Дәүләт Советына еллык юлламасында әйтте. «Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз. Бу безгә буыннар бәйләнешен тирәнтен тояргa, киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә», – диде Рөстәм Миңнеханов. Татарстан Рәисе 2025 елда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтеләчәген искәртте. «Ул Җиңү – безнең төп горурлык. Бүген бездә булганнар белән фронтта һәм тылда җиңү өчен көч куйган ветераннарга бурычлыбыз. Кызганыч, Бөек Җиңүнең тере шаһитләре көннән-көн кими. Һәр ветеранны кайгырту мөһим. Муниципаль берәмлек башлыкларына, башкарма хакимият органнары җитәкчеләренә тиешле чараларга әзерлекне югары дәрәҗәдә оештыруларын сорыйм», – дип мөрәҗәгать итте Миңнеханов.

Яңа 2025 ел һәр йортка иминлек, гаиләләргә тынычлык, муллык һәм бәхет-шатлыклар алып килсен! Сезнең һәрберегезгә рух ныклыгы, күңел көрлеге һәм сәламәтлек телибез.

Ил-көннәребез тыныч, имин, 2025 ел яңа уңышлар, яңа җиңүләр һәм бәхетләр елы булсын!












Билгеле булганча, Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итте. Безнең районда да шушы уңайдан күп чаралар планлаштырыла. 26 гыйнварда районда шушы елны ачуга старт биреләчәк. Бу көнне Арча шәһәреннән төрле юнәлештә гуманитар ярдәм төялгән машиналар колоннасы юлга кузгала. Бакчабызда әлеге гуманитар колоннаны формалаштыруда катнашу максатыннан акция игълан ителде. Әти-әниләр һәм бакча хезмәткәрләре тарафыннан егетләр өчен шоколад конфетлар, чәй,кофе, тиз әзерләнә торган боткалар җыелды.








Бакчабызда искечә Яңа елны бәйрәм иттек. Гадәт буенча, аны 13 гыйнвардан 14 енә каршы иске стиль буенча билгелиләр. Үз тарихында ел исәбен алыштырган һәр илдә искечә Яңа ел – рәсми булмаган күңелле бәйрәмнәрнең берсе. Бүген балалар шундый матур, шундый гаҗәеп, шатлыклы, көлкеле җәнлекләргә, матур кар бөртекләренә әверелделәр, шигырьләр сөйләделәр, биеделәр. Мавыктыргыч уеннар балаларны сихри дөньяда йөзәргә, кунак булып килгән Убырлы карчык белән көлкеле могҗизалар иленә сәяхәт кылдырды. Бәйрәм «Иске ел» ны озату күренеше белән үрелеп барды.




**« Новогодняя феерия » конкурсында**
**III урын**



13 гыйнвар көнне «Арча» үзәк стадионында «Чыршы ябылышы» чарасы һәм Яңа ел бизәлеше буенча бүләкләү тантанасы булып узды.
Наласа балалар бакчасы территорияне Яңа елга бизәү буенча уздырылган «Новогодняя феерия» конкурсында катнашып, III дәрәҗәдәге дипломга лаек булды. Әлеге эштә актив катнашкан бакча хезмәткәрләренә, тәрбиячеләргә, эти-әниләргә зур рәхмәтебезне белдерәбез. Бердәмлектә - көч!!!


ДИПЛОМ
НАГРАЖДАЕТСЯ
МБДОУ «Наласинский детский сад»
(директор Гафурова Эльмира Рашатовна)
III место
за новогоднее оформление подведомственной территории в конкурсе «Новогодняя феерия»
Глава Арского муниципального района И.Г. Нуриев
Арск, 2024-2025



    

**“Кышлаучы кошлар-безнен дусларыбыз”**

Җир шарында 9600 төрле кош яши. Татарстанда 200 төрдән, кыш айларында 40 лап төр кош очратырга була. Кошлар һавада очарга җайлашканнар. Шуңа күрә алар кеше аягы басмаган урыннарда да яшиләр. Бер илдән икенче илгә, таулар, урманнар һәм диңгезләр аша күчеп китү кошлар өчен авыр түгел. Кошлар бик тиз очалар. Кызганычка каршы җир йөзеннән кошларның 94 төре бөтенләй юкка чыкты, ә тагын 187 төре Кызыл китапка кертелгән. Кошларның күбесе кыш көне салкыннар башлангач, ачлыктан һәлак булалар. Кыш көне кошлар кешеләр ярдәменә мохтаҗ, ләкин бу эшне дә бик белеп кенә башкарырга кирәк. Әгәр кошларга дөрес азык бирмәсәк, без аларга зыян гына китерәбез. Бу турыда “Кошлар дөньясы” китабыннан укыгач, без уйга калдык, ә безнең авыл тирәсендә нинди кошлар яши соң? Әгәр кош ач булса, ул теләсә нинди җимлектән, теләсә нинди азык ашый микән? Карга, күгәрчен, кызылтүш,песнәк , тукран, чыпчык чукыр, үрмәләч, миләш чыпчыгы. Бу кошлар - кышлаучы кошлар. Шул кошлардан карга, күгәрчен, кызылтүш,песнәк , тукран, чыпчык, миләш чыпчыгын безнең авыл тирәсендә дә очратырга була. Кошлар авыр вакытны үткәрү өчен төркемнәргә җыелалар. Берсе азык тапса,барысына да хәбәр итә. Башкалар ашаганда яки ял иткәндә берсе сакта тора. Бергә булганда зуррак ерткычлардан котылу җиңелрәк икән. Кошларга суык куркынычмы,әллә ачлыкмы?. Әгәр кошлар тук булса, алар салкыннарга бирешмиләр икән. Кошларга теләсә нинди азык бирергә дә ярамый икән. Туңмайны агач ботагына элеп тә куеп була, ләкин тозлы май ярамый. Ак ипине киптереп, ваклап бирергә кирәк. Туңган зур кисәкләрне алар чукый алмыйлар. Кара арыш ипие кошларга зыянлы. Шулай ук кошларга борчак, перловка ярамый. Ашказанында бүртеп алар кошларны үлемгә китерәләр. Ярмалардан алар геркулес, тары ярмасын яраталар. Шулай ук миләш җимеше, каен, нарат, чыршы, карагай, зирек орлыкларн да теләп ашыйлар. Без кошларга азык тупланмасы әзерләү өчен башта аларның нәрсәләр ашаганнарын белдек.

Карабүрек- көнбагыш, кабак, карбыз орлыклары белән туклана

Песнәк- агач һәм куак каерыларындагы бөҗәкләр белән туклана, җимлеккә дә бик рәхәтләнеп очып килә.

Чыпчык -ярма, төрле орлыклар, ипи валчыкларын яратып ашый.

Миләш чыпчыгы- Миләш һәм балан җимешләре белән туклана.

Ала карга- Яшелчә кабыклары һәм теләсә нинди азык калдыклары белән туклана.

Песнәкләр – бик хәрәкәтчән кошлар. Алар бер агач ботагыннан икенчесенә сикереп уйныйлар, башаркан торырга яраталар, ботакта атыналар, хәтта иң нечкәсендә дә асылынып кала алалар. Бу очракта аларга озын һәм очлы тырнаклары ярдәмгә килә.

Безнең якларда бигрәк тә тукраннар очрый. Тукран –урманнарыбызның гүзәллеге ул. Тукран – тырыш, хезмәт сөючән кош. Алар агачлардан төрле корткыч бөҗәкләрне чүплиләр. Шулай итеп, агачларга гомер өстиләр.

Карабүрекләр – бик чибәр кошлар. Аларның түше ут янып тора. Карабүрекләр 7-10 лап булып төркемләнәләр. Салкын никадәрле көчле булса, кошлар төркеме дә шуның хәтле тыныч утыра, аз хәрәкәтләнә. Караңгы төшә башлауга алар агач-куаклар астына качалар һәм шунда төн үткәрәләр.

Саескан – бик шома, хәрәкәтчән, кайгыртучан кош. Шуңа күрә кышкы салкыннарда алар кешеләр яши торган җирләргә якынлашалар, тәрәзә артларында йөреп, “кунак киләсен” хәбәр итәләр.

Кышын кошларга бик кыен. Кыска көннәрдә, азык табып, тамакларын туйдырырга да өлгермиләр, инде кич килеп җитә. Бозлавык вакытларда аларга агач кәүсәсе буйлап ризык эзләве тагын да кыенлаша. Шулай итеп, бик суык көннәрдә күп кенә кошлар катып үләләр. Мәсәлән, мондый чакларда 10 песнәктән бары 1 генә песнәк исән кала икән. Менә шуңа күрә без кошларга кышын ярдәм итәргә тиешбез.

Һәр елны балалар кошларга җимлекләр әзерли. Бу атнада да әти-әниләр ярдәме белән җимлекләр ясап, аларны бакча һәм өйләре янындагы агачларга элеп куйдылар. Балалар бакчасыннан ук балалар кышлаучы кошларны таныргa, аларның тормышы белән кызыксынарга өйрәнәләр Аларга ярдәм итәргә, табигатькә карата мәрхәмәтле булырга кечкенәдән өйрәтү мөһим.









**Песнәк**

**Бакчадагы җимлегемә,**
**Килеп кунды бер песнәк.**
**Аны күргәч алып чыктым,**
**Ашарына мин икмәк.**
**Ә песнәгем бик шатланды,**
**Канатын кага-кага.**
**Тик сөенеп туя алмады,**
**Килде берничә карга.**
**Песнәк карышып тормады,**
**Очып китте еракка.**
**Ә мин яңадан бер җимлек,**
**Элеп куйдым шул якка.**
**Көн саен мин ярма салам,**
**Кошлар җим чүпли иртән.**
**Ә мин алар тавышында,**
**Гүя рәхмәт ишетәм.**

**Зилә Гыйльманова**



## Шагыйрә Гөлчирә Нәҗметдинова белән очрашу кичәсе










*Шигырь бит ул һәрбер юлы белән*

*Күп нәрсәне сөйли, аңлата…*

(Гөлчирә Нәҗметдинова)

18 нче гыйнвар көнне Наласа авыл китапханәсендә Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, авылдашыбыз, балалар шагыйрәсе Гөлчирә Нәҗметдинова белән очрашу кичәсе узды. Кичәдә “Балачак” балалар бакчасына йөрүче балалар, башлангыч сыйныф укучылары, тәрбиячеләр, укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре Гөлчирә Нәҗметдинова иҗат иткән “Кар өстендә кызыл алма” дип аталган яңа шигырьләр җыентыгыннан шигырьләр укыдылар. Иң нәни китап укучыларыбыз башкаруында без шагыйрәнең саннар, җиләк-җимешләр турындагы шаян шигырьләрен тыңладык. Шигърият бәйрәме, бер сулышта, бик күңелле узды. Чара ахырында Гөлчирә Нәҗметдинова барлык катнашучыларга да зур рәхмәтләрен белдерде.

Китапханәче Гөлчәчәк Сабирҗанова



Мин бик тә кәнфит яратам!

Гел кәнфит ашар идем...

Хәлемнән килсә, кәнфиттән

Зур таулар ясар идем...

Гөлчирә Нәҗметдинованың "Кәнфит тавы" шигыренә кул эше.

Сабирҗанов Хәмзә ("Кояшкай" төркеме)

***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Шагиева А.К., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Хөсәенова Р.Н., Гафурова Р.А., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*